**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7585**
**23.11.2021**

«Чаллыда Яңа ел-2022»
бәйрәме чараларына әзерлек
һәм аларны үткәрү турында

Шәһәр традицияләрен саклау, Яңа ел бәйрәмнәре чорында шәһәр халкының оешкан төстә ял итүе өчен шартлар тудыру, «Чаллыда Яңа ел-2022» гомумшәһәр бәйрәм чараларына әзерлек һәм аларны үткәрү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «Чаллыда Яңа ел-2022» бәйрәме чараларын, яңа коронавирус инфекциясе таралу куркынычы белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән чикләү чаралары үтәлешен тәэмин итә торган формада, 2021 елның 13 декабреннән 2022 елның 13 гыйнварына кадәр үткәрергә.

2. Расларга:

1) «Чаллыда Яңа ел-2022» бәйрәме чараларына әзерлек һәм аларны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 1 нче кушымтада каралганча;

2) «Чаллыда Яңа ел-2022» бәйрәме чараларына әзерлек һәм аларны үткәрү буенча оештыру-хуҗалык чаралары планын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Шәһәр оешмаларына һәм физик затларга «Чаллыда Яңа ел-2022» бәйрәме чараларына әзерләнү һәм үткәрүгә ирекле иганәләрнең түбәндәге исәп-хисап счетына күчерелү турындагы мәгълүматны җиткерергә: Мәдәнияткә, спортка һәм Яр Чаллы шәһәрен үстерүгә ярдәм фонды. Юридик адресы: 423808, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Габдулла Тукай исемендәге яр буе, 31 йорт.

ИНН 1650305925   КПП 165001001
р\сч 40703810000000000196   «АКИБАНК» ААҖ
БИК 049205933 к\сч 30101810622029205933.
Түләү билгеләнеше: ирекле взнос.

4. Тәкъдим итәргә:

1) Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы идарәсенә (Закиров Н.Д.) чаралар үткәрү урыннарында гражданнар иминлеген һәм җәмәгать тәртибен тәэмин итүгә ярдәм күрсәтергә;

2) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенә чаралар үткәрү урыннарында беренче чираттагы медицина хезмәте күрсәтүне оештырырга.

5. Районнар территориясендә «Чаллыда Яңа ел-2022» бәйрәме чараларын оештыру һәм үткәрү өчен җаваплылыкны Башкарма комитетның Үзәк районы

хакимияте Башлыгы И.Н. Галимовка, Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ф.Ф. Хәбибуллинга йөкләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов